ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРУССИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Старые Уруссу, ул.Советская, д.16в,
423960

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Иске Урыссу авылы, Совет урамы,
16в йорт, 423960

Тел.:(85593) 4-42-31, факс:4-42-10, e-mail: Uruss.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 8 13 февраль 2026 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның 25 апрелендәге 5 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең балалар уен һәм спорт мәйданчыкларында балалар мәйданчыкларын, уен һәм спорт җиһазларын тоту һәм эксплуатацияләү, җиһазларның техник торышын һәм куркынычсыз эксплуатациясен тикшереп торуны оештыру кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 210-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы,Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Урыссу авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге башкарма комитетының 2025 елның 25 апрелендәге 5 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең балалар уен һәм спорт мәйданчыкларында балалар мәйданчыкларын, уен һәм спорт җиһазларын тоту һәм эксплуатацияләү, җиһазларның техник составын һәм куркынычсыз эксплуатациясен тикшереп торуны оештыру кагыйдәләре”нә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Кагыйдәләрнең 4.2 пунктындагы 3 пунктчасының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Функциональ карау җайланманың төзеклеген һәм тотрыклылыгын тикшерү, җайланма конструкциясе элементларының тузганлыгын ачыклау максатында җентекле караудан гыйбарәт. Тикшерүне җитештерүче инструкциясе нигезендә өч айга бер тапкыр үткәрәләр. Җиһазларның яшерен, авыр үтеп керә торган элементларына аерым игътибар бирәләр.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында

таныклык) һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын урнаштырырга. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адресы буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Әминова